РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

Кукмара ш.

7 ноябрь, 2025 ел № 20

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен тәңгәлләштерү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү башлангычын кертергә. (1 нче кушымта).


2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр чикләрен тәкъдим ителгән туры китерү буенча фикер белдерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы аша халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук гражданнар күпләп җыела торган урыннарда Мәмәшир авыл җирлегенең җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кукмара муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Н. Гаяновага йөкләргә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Кукмара муниципаль районы Советының 2025 елның 7 ноябрендәге 20 номерлы




карарына кушымта